МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9,г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

Кремльур., 9нчыйорт,Казан шәһәре,420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№_______________

На №________________от________________

**Татарстан Республикасы муниципаль районнары башкарма комитетларының мәгариф идарәләре (бүлекләре) җитәкчеләренә**

Укучылар өчен республикакүләм Гамил Афзал исемендәге иҗат фестивален үткәрү турында

**Хөрмәтле җитәкчеләр!**

Татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү, укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уяту, әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне ачыклау, барлау, яшь язучыларны таныту, осталыкларын үстерергә ярдәм итү максатыннан, 2016-2017 нче уку елында Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты һәм Актаныш муниципаль районы Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернаты белән берлектә татар телендә иҗат итүче мәктәп укучылары арасында республикакүләм Гамил Афзал исемендәге иҗат фестивален уздыра.

Бәйгедә катнашу өчен, укучыларның иҗади эшләрен электрон вариантта venerahaeva@yandex.ru адресына 2017 елның 5 нче апреленә кадәр җибәрү сорала. 1 нче турда җиңеп чыгучыларга бәйге лауреаты исеме бирелә, 1-3 нче урыннар алучыларга Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы дипломнары һәм премияләр тапшырыла.

Йомгаклау кичәсен уздыру көне өстәмә рәвештә игълан ителәчәк.

Хәбәрләшү өчен телефоннар: 89172573988 (Хәева-Хәмитҗанова Венера Хәмәтнәсих кызы).

Кушымта: 3 биттә 1 нөсхәдә.

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр** **Э.Н.Фәттахов**

Л.Р.Зайнуллина
8(843) 294 95 10

Кушымта

Укучылар өчен республикакүләм
Гамил Афзал исемендәге иҗат фестивален үткәрү турында

**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми мәгълүмат

1.1. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты, «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле гомумбелем учреждениесе белән берлектә күренекле шагыйрь, Гамил Афзал иҗатына багышланган республикакүләм иҗат фестивале үткәрә.

## 2. Фестивальнең бурычлары

- Яшәгән төбәкнең тарихын, бүгенге сулышын өйрәнү.
- Балаларда һәм яшүсмерләрдә туган як табигатенә, авыл кешеләре язмышына, тормыш-көнкүрешенә мәхәббәт тәрбияләү.
- Ата-бабаларыбыз мирасын барлау.
- Балаларның, яшүсмерләрнең иҗади мөмкинлекләрен үстерү, журналистика, әдәбият, сәнгать, мәдәният өлкәләрендә интеллектуаль иҗат эшчәнлекләрен киңәйтү.
- Яшь язучыларны таныту, осталыкларын үстерергә ярдәм итү.

## 3. Катнашучылар

Республикакүләм Гамил Афзал исемендәге иҗат фестивалендә 5-11 сыйныф укучылары катнаша ала. Эшләр мөстәкыйль эшләнгән, мәгълүматлар анализланган һәм аларда авторның үз карашы, фикере чагылырга тиеш.

## 4. Бәйгене оештыру комитеты

4.1. Бәйгене үткәрү өчен Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты, «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле гомумбелем учреждениесе, яшьләр өчен чыга торган массакүләм мәгълүмат чаралары, белем оешмалары вәкилләреннән торган оештыру комитеты төзелә.

4.2. Оештыру комитеты Фестиваль турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы сайты, республика муниципаль районнарының мәгариф идарәләре яки бүлекләре аша мәктәпләргә җибәрелгән мәгълүмат хатлары, балалар һәм яшүсмерләр өчен чыга торган татар газета-журналлары аша мәктәп укучыларына, киң җәмәгатьчелеккә җиткерә, әсәрләрне

туплауны һәм жюри эшчәнлеген оештыра. 2 нче турга чакырылган җиңүчеләр өчен татар язучылары, шагыйрьләр белән очрашулар, остаханәләр, түгәрәк өстәлләр һәм бүләкләү тантанасын үткәрә, яшь язучыларның әсәрләрен таныта.

## 5. Катнашучыларга һәм иҗади эшләргә таләпләр

5.1. Бәйгедә татар телендә иҗат итүче мәктәп укучылары катнаша ала.

5.2. Бәйгегә җибәрелгән әсәрләр өч яшь категориясенә бүленеп карала:

1. 5 - 7 сыйныфлар;
2. 8 - 9 сыйныфлар;
3. 10-11 сыйныфлар.

5.3. Бәйге түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

- Журналистик һәм публицистик әсәрләр (Шигъриятҗә һәм прозада Гамил Афзал образы);
- Поэзия (лирик шигырьләр);
- Поэзия (юмор – сатира әсәрләре);
- Гамил Афзал иҗаты – рәсем сәнгатендә;
- Гамил Афзалның юмористик шигырьләренә пародия.

5.4. Фестивальдә катнашучы теләсә кайсы номинациядә татар телендә иҗат иткән әдәби әсәрен тәкъдим итә. Берьюлы 2-3 номинациядә катнашырга мөмкин.

5.5. Әсәр матбугат битләрендә яки китап буларак басылган булырга мөмкин. Каләмдәше (соавторы) мәктәп яшендә булмаган, республика күләмендә оештырылган башка әдәби бәйгеләрдә катнашкан әсәрләр кабул ителми.

5.6. Эшләренең бизәлешенә таләпләр: word документы, А4 форматы, Times New Roman шрифты 14, 1,5 интервал, читләрдән 2 см. Эшләр электрон форматта гына җибәрелә. Рәсемнәр А3 форматында булырга тиеш.Анкета белән бергә түбәндәге адреска җибәрелә 423740, Актаныш авылы, Аэропортлы урамы, 3 а нче йорты.

## 6. Фестивальне үткәрү тәртибе

6.1. Бәйгедә катнашучы үзе (яшьтәш соавторы булса, үзләре) иҗат иткән әсәрне (берничә номинациядә катнашса, әсәрләрне) һәм үзе турындагы анкетаны (кушымта) оештыру комитетына venerahaeva@yandex.ru адресына 2017 елның 5 нче апрель көнне 18.00 сәгатькә кадәр юллый.

6.2. Фестиваль ике турда уздырыла:

1 нче тур. 15 нче март – 5 апрель. Экспертлар төркеме барлык әсәрләр арасыннан 30 шигырь (һәр яшь категориясендә 10 ар), 30 журналистик һәм публицистик әсәре,30 рәсем сайлап ала.

2 нче тур. 5 нче апрель – 20 нче апрель. Жюри 1 нче турда сайлап алынган әсәрләрнең бәяләмәсен карап чыгып раслый һәм алар арасыннан һәр яшь категориясендә 1 нче урын, 2 нче урын, 3 нче урынны билгели.

1 нче турда җиңгән һәркемгә бәйге лауреаты исеме бирелә һәм җиңүчеләр барысы да йомгаклау кичәсенә чакырыла. Башлангыч сыйныф укучылары әсәрләре арасыннан иң яхшылары сайлап алынып, аларның авторларына йомгаклау кичәсендә кызыксындыру бүләге тапшырыла.

1 нче турда сайлап алынган әсәрләрдән әдәби альманах бастырыла, алар Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы язучылар берлеге, Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат сайтына урнаштырыла.

6.3. Фестиваль нәтиҗәләре, җиңүчеләр турында мәгълүмат Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат сайтына урнаштырыла.

**АНКЕТА**

Фамилия, исем: ______________________________________________
Туган елы: __________________________________________________
Район: _____________________________________________________
Шәһәр: _____________________________________________________
Мәктәп______________________________________________________
Сыйныфы: ___________________________________________________
Өстәмә мәгълүмат (ирекле): ____________________________________
_____________________________________________________________
Әсәр исеме: _________________________________________________
Номинация:__________________________________________________
Әсәр күләме (бит): ____________________________________________
Басылып чыккан әсәрләре, еллары, кайда: _________________________
Хәбәрләшү өчен телефон: _______________________________________
Электрон адрес:_______________________________________________
Өй адресы:___________________________________________________

Лист согласования к документу № исх-396/17 от 06.03.2017
Инициатор согласования: Зайнуллина Л. Р. Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 06.03.2017 13:30

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано 06.03.2017 - 14:46 | - |
| 2 | Исмагилова Г.Х. | | Согласовано 06.03.2017 - 15:01 | - |
| 3 | Мухаметов И.Р. | | Согласовано 06.03.2017 - 18:13 | - |
| 4 | Фаттахов Э.Н. | | Согласовано 06.03.2017 - 18:28 | - |